### КЕМ ЭШЛИ?
**Аксубай районында яшәүче фермер Ильяс Сөләйманов авылның киләчәге өчен кайгыра**

> 2

### МАРАТ КӘБИРОВ:
**«Бөтен дөньяны яулау турында сөйләнсәк тә, безнең үз дөньябыз шушында бит инде»**

> 3

### КӨЗГӘ АВЫШТЫК
**Шушы вакыт җитсә, авыл кешесе инде күңеле белән көзге эшләрне барлый башлый**

> 3

### ОЧРАШУ УРЫНЫ
**7–11 сентябрьдә Казанда Халыкара мөселман киносы фестивале узачак**

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 118 (28891) | Сишәмбе | 16 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


**Татарстанда сатылган искерткеч күләме 6 процентка арткан. Быелның алты аенда Татарстанда 2,75 миллион декалитр хәмер сатылган. Белгечләр моны соңгы тугыз елдагы рекордлы сан дип бәяли. Соңгы тапкыр мондый күрсәткеч 2013 елда теркәлгән булган. Ул чакта республикада 2,97 миллион декалитр исерткеч сатылган. Иң кечкенә саннар (2,57 миллион декалитр. – Авт.) исә 2015 елда теркәлгән. Бу саннар нәрсәне аңлата? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

# КУРКЫНЫЧ ШЕШӘ
## ТАТАРСТАНДА САТЫЛГАН ХӘМЕР КҮЛӘМЕ НИ СӘБӘПЛЕ АРТКАН?

Быел иң күп хәмер Питрәч районында сатылган. Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүматларына караганда, биредә яшәүчеләр алты ай дәвамында барлыгы 37,5 мең дал спиртлы эчемлек сатып алган. Бу, алдагы елның шушы чоры белән чагыштырганда, 19 процентка күбрәк. Исерткеч эчемлекләр сату иң нык арткан 10 район арасына Югары Ослан, Яңа Чишмә, Тукай, Лаеш, Кайбыч, Спас, Баулы, Апас, Буа һәм Кукмара да кергән. Казанда исә быел, алдагы ел белән чагыштырганда, 4 процентка күбрәк хәмер сатылган.

Психотерапевт, «Яшәү территориясе» социаль инициативалар үзәге башлыгы Антон Миронов Татарстанда хәмернең күбрәк сатыла башлавын соңгы арадагы вакыйгалар нәтиҗәсе дип саный.

– Соңгы арада дөньяда, илдә барган вакыйгалар җәмгыятьтәге киеренкелекне арттыра. Кагыйдә буларак, стресс арткан җирдә исерткеч эчемлекләр дә күбрәк кулланыла. Шул ук 1990 нчы елларда да бик каты эчәләр иде. Моңа, нигездә, тормыш дәрәҗәсенең түбәнлеге, эшсезлек сәбәпче булды. Бүгенге тотрыксыз тормыш, шул ук эшсезлек кабат теңкәгә тия. Инфляция бик зур. Элегрәк кеше айлык кеременең бер өлешен җыеп та бара алган булса, хәзер бу мөмкин түгел. Көн дә ишетелеп торган күңелсез хәбәрләр дә кешенең психофизиологик халәтенә тискәре йогынты ясый. Кеше аз булса да онытылыр, киеренкелектән котылыр өчен хәмергә үрелә, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Татарстанның алкоголь ассоциациясе рәисе Ләйсән Шишкина да шул фикердә. «Моңа, иң беренче чиратта, кешеләрнең әле һаман да булса киеренке халәттә яшәве сәбәпче. Пандемия чорында башланган бу стресс, махсус операция җәелдерелгәч, тагын да көчәйде. Моңа чикләрнең ябылуы, Татарстанда хәмер сатылу вакыты озайтылу да йогынты ясады», – ди белгеч.

Билгеле булганча, март аеннан Татарстанда исерткеч эчемлекләр сату вакытын өч сәгатькә озайттылар. Моңарчы бездә хәмерне кичке сәгать уннан иртәнге унга кадәр сатутыелган иде. Хәзер исә аны иртәнге сигездән төнге унбергә кадәр саталар. Бу тәкъдимнең авторы – Татарстан Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллин сүзләренә караганда, бездә исерткеч эчемлекләрнең өч сәгатькә кимрәк сатылуы республика бюджетына шактый бәргән. Чикләүнең һәр сәгате эчендә бюджетка тиешле акчаның 9 проценты керми калган. Шул рәвешле хәмер сату вакыты чикләнгән өч ел вакыт эчендә республика бюджетына 1,5 миллиард сум чамасы акча керми калган. Бу – елына 560 миллион сум дигән сүз.

Депутатлар хәмер сату вакытын озайтуны республика казнасы өчен файдалы булачак дип тынычландырган көннәрдә, бу үзгәрешнең тискәре яклары күренәчәген фаразлаучылар да булды. Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов, бер сөйләшүебездә, хәмер сату вакытын озайту белән аны кулланучылар саны да артырга мөмкин, дип белдергән иде. «Аракы күбрәк сатылгач, аңа бәйле җинаятьчелек, имгәнү, үлем-китем, гаиләләр таркалу, балалар ятим калу кебек тискәре күренешләр дә артачак дигән сүз. Аларны шулай ук республика бюджеты хисабына хәл итәргә туры киләчәк. Шуңа хәмер сату вакытын озайту безгә бик кыйммәткә төшәчәк», – дигән иде ул.

Алайса, нишләргә? Казан дәүләт медицина университетының клиник психологы Эльмира Миассарова сүзләренә караганда, үзәк нерв системасы аеруча сизгер булган кешеләр стресска тизрәк бирешә. Белгеч әйтүенчә, тормышта үз өстенә җаваплылык алырга күнекмәгән кеше дә бүгенге катлаулы вазгыятьтә бик тиз «сына». Андыйлар арасында, кыенлыкларга түзә алмыйча, кыек юлга кереп китүчеләр, начар гадәтләргә бирешүчеләр дә байтак.

– Бүгенге шартларда үз-үзеңне югалтмас, төшенкелеккә бирелмәс өчен, иң беренче чиратта, вазгыятьнең үзгәрүе бездән генә тормавын аңларга кирәк. Булдыра алган кадәр тынычлык сакларга кирәк. Монда инде контраст душ, мунча керү, саф һавада йөрү кебек гади генә әйберләрдән башлап, якыннарың белән күрешү, кунакка йөрешү, яраткан эшең белән шөгыльләнү кебек бар нәрсә ярдәмгә киләчәк. Бүгенге тотрыксыз заманда берәр яңа һөнәр, шөгыль үзләштерү дә комачауламас. Нәрсә генә эшләсәгез дә, гел хәрәкәттә булыгыз, кыскасы.

Бер начарның бер яхшысы дигәндәй, белгечләр күпләп хәмер сатылуның да уңай якларына игътибар итәргә чакыра. Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов та шул фикердә. «Чит илләр белән мөнәсәбәтләрнең тотрыксыз булуы, чикләүләр аркасында бүген күпләр үзебездә генә ял итәргә мәҗбүр. Бу берникадәр эчке туризмның үсүенә китерә. Нәтиҗәдә үзебездә спиртлы эчемлекләр кулланучылар саны арта. Исерткеч эчемлекләр күбрәк сатыла башлау җәмгыять өчен бик үк уңай күренеш булмаса да, акциз маркалары аркылы, бюджетка керем артуга китерә, шул рәвешле икътисадка да ярдәм итә», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХӘМЕР САТУ АРТКАН РАЙОННАР

| | |
|---|---|
| Питрәч | +19% |
| Югары Ослан | +17% |
| Яңа Чишмә | +16% |
| Тукай | +15% |
| Лаеш | +13% |
| Кайбыч | +13% |
| Спас | +12% |
| Баулы | +9% |
| Апас | +9% |
| Буа | +9% |
| Кукмара | +9% |



## Акчаны арттырдылар

Татарстанның «Алга» һәм «Тимер» батальоннары хәрби хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган акча күләме 100 мең сумга арттырылган. Моңа кадәр бу 260 мең булса, хәзер 360 мең сумга җиткән. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов шул хакта тиешле указга кул куйган.

Карар республика батальоннарында хезмәт итүчеләргә ярдәм күләмен арттыру йөзеннән кабул ителгән. Исегезгә төшерәбез: «Алга» һәм «Тимер» хәрбиләренә бер тапкыр түләү өлешләп бирелә. 60 мең сум күләмендәге беренче түләү хәрби часть исемлекләренә кертелгәннән соң, атна саен 15әр мең сум күчерелә. Калганын хәрби хезмәткәрләр махсус операциядә катнашу өчен Россия чикләре аша узгач ала.

«Татар-информ» хәбәр итүенчә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт торак фондына «Алга» һәм «Тимер» батальоннары хәрби хезмәткәрләре өчен яңа программа әзерләргә кушкан.

## *Эшләгәнгә... ярдәм язган*

Татарстанда оешманың бетерелүе яки туктап калуы сәбәпле эштән китү янаган кешеләргә яңа ярдәм чаралары кертелгән. Мондыйлар шәхси эшмәкәр, фермер хуҗалыгы милекчесе сыйфатында теркәлгән очракта, бер тапкыр түләү алырга мөмкин. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган.

Документ нигезендә, шәхси эшмәкәр булып кына түгел, ә үзмәшгуль булып теркәлгәндә дә акча биреләчәк. Әлеге ярдәмгә мәшгульлек үзәкләрендә теркәлгән эшсезләр, оешмасы бетерелү алдында калган, шулай ук тулы булмаган эш көненә күчерелгән хезмәткәрләр исәп тотарга мөмкин. Моннан тыш аны түләүсез ялга җибәрелүчеләр дә алачак.

## Бурычлыга көн беткән

Татарстан суд приставлары быел 7 ай эчендә алимент буенча барлыгы 348 миллион сумлык бурыч түләткән. Узган елның шушы ук чорында 301 миллион сум чамасы түләтелгән булган.

Алиментын вакытында түләмәүчеләргә мәҗбүриләү чаралары кулланыла. 7 айда приставлар бурычлыларның 1226 милкенә арест салган, 2415 кешегә машинасын идарә итү хокукын чикләү, 10271енә чит илгә чыгуны вакытлыча чикләү турында карар чыгарган, 1522се административ җаваплылыкка тартылган.

Суд приставлары идарәсе искә төшерә: ел башында законга, алимент түләмәүчеләрне, балаларын һәм эшкә яраксыз ата-аналарын карауга өлешчә акча түләсә дә, административ һәм җинаять җаваплылыгына тартуны күздә тоткан үзгәрешләр кертелгән. Моңа кадәр алиментын өлешчә түләүчеләр мондый җаваплылыктан котылып калган.

Быел алиментын тулысынча түләмәүче 126 кеше җинаять җаваплылыгына тартылган инде.

COVID-19

# Яңа дулкын

**Тынычланган күңелләр кабат дулкынланырга мәҗбүр. Коронавируска бәйле рәсми статистика кабат сагайта. Дөнья күләмендә COVID-19 инфекциясен ияртеп авыручылар саны бер миллионга җитте. Бу – бер тәүлектә. Ә Россия һәм Татарстандагы саннар ни сөйли?**

Узган атнада коронавирус белән чирләүчеләр саны ил күләмендә 50 процентка артты. Оператив штабның соңгы мәгълүматларына күз салсаң, бер тәүлектә инфекция йоктырып авыручылар саны 25273кә җиткән. Бер көндә 1581 кешене хастаханәгә салганнар. Сәламәтләнеп чыгучылар саны – 15410. Кызганыч, чир 53 кешенең гомерен өзгән.

Роспотребнадзор хәзерге көндә эпидемиягә каршы илкүләм чикләүләрне яңадан булдырырга нигез юк дип хәбәр итсә дә, кайбер белгечләр коронавирусның яңа дулкыны куркыныч булмагае дип тә фаразлый.

Россия Фәннәр академиясенең Молекуляр генетика институты лабораториясе мөдире, профессор Константин Северинов сүзләренчә, яңа төрле штаммнар барлыкка килүгә бәйле рәвештә вируслы вазгыять шактый кискенләшергә мөмкин.

– Хәзер вирусның яңа төрләре барлыкка килде, алар прививкадан соң яки вирус белән авырудан соң барлыкка килгән иммунитетны җиңәргә сәләтле. Россиядә вакцина ясаткан кешеләр саны да аз. Сүз ревакцинация турында түгел. Болар барысы да вазгыятьнең кискенләшүенә китерергә мөмкин, – ди белгеч. – Шунысы да бар: яңа дулкын үлүчеләр санының артуына китермәде.

Рәсми саннар буенча, Россиядә коронавирустан көненә 50ләп кеше үлә. Ул май күрсәткечләреннән әллә ни үзгәрмәде. Күрәсең, коронавирусны кеше җиңелрәк кичерә башлады. 2020–2021 елларда Россиядә бу инфекциядән үлүчеләр шактый булды.

Профессор сүзләренә караганда, хәзер төп бәла – чир йоктыручылар саны арту. «Инфекцияле кешеләр күбрәк булган саен, вирусның тагын да көчлерәк төрләре барлыкка киләчәк. Вирусны контрольгә алуның бердәнбер ысулы – кешеләр арасында аның таралышын чикләү», – дип саный Константин Северинов. Барыннан да элек моны вакцинация юлы белән эшләп була.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

**Илсур МЕТШИН, Казан мэры:**

Казан зур тизлек белән үсә. Соңгы елларда без бистәләрдә яшәүчеләр санының бик нык артуын күзәтәбез. Шәһәр халкы үз йортында яшәргә тели. Ләкин моның икенче ягы да бар: инфраструктура юк. Бистәләрдә җир сатып алганда, нинди шартларда яшәячәгеңне дә исәпкә алырга кирәк. Бу проблема белән озак еллар дәвамында көн саен очрашырга туры киләчәк.

**(«Эшлекле дүшәмбе»дәге чыгышыннан)**

## «БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ» ПРОГРАММАСЫ

**Татарстанда Президентның «Безнең ишегалды» программасын тормышка ашыру дәвам итә.**

Яктырту эшләренең **81 проценты** башкарылган. **638** ишегалдында тәмамланган

Юл эшләренең **85 проценты** башкарылган. **644** ишегалдында тәмамланган

Җиһазларның **52 проценты** урнаштырылган. Бу эш **738** ишегалдында алып барыла.

Программа буенча быел **1200**дән артык ишегалдын тәртипкә китерү каралган.

## *Хәерле юл!*

Беренче яртыеллыкта Татарстан юлларында һәлакәтләр саны азайган. Республика шушы чорда хәтәр очраклар буенча Россия төбәкләре арасында 52 нче урында. Узган ел белән чагыштырганда, аварияләр 7,7 процентка кимегән. «РИА рейтинг» тикшеренүендә шул хакта әйтелә.

Белгечләр мәгълүматлары буенча, гыйнвардан июньгә кадәрге чорда республикада 100 мең автомобильгә 107,6 куркыныч очрак туры килгән. Аварияләрдә имгәнүчеләр һәм һәлак булучылар күрсәткече 100 мең кешегә 50,1не тәшкил иткән. Юлларда һәлак булучылар – 3,1 процентка, җәрәхәтләнүче-имгәнүчеләр 7,2 процентка азрак теркәлгән.

Беренче яртыеллык рейтингында Чечня беренче урынга чыккан: биредә гыйнвардан июнь аена кадәр юллардагы куркыныч хәлләр узган елның шушы ук айлары белән чагыштырганда 42,2 процентка кимрәк булган. Ямал-Ненец автономияле округы – икенче, Томск өлкәсе – өченче урында.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

## МИНЕ КҮРСӘҢ, ЕЛА…

Киеренкелек, өметсезлек, чарасызлык… Планетада барган вакыйгаларның күбесен, кызганыч, шундый сүзләр белән бәяләргә мөмкин. Хәлләр өченче дөнья илләрендә дә, үзләрен алтын миллиардка керткән халыклар яшәгән төбәкләрдә дә катлаулы.

АКШта Pew (Pew Research Center) дип аталган үзәк американнар арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләрен игълан итте. Халыкның 72 проценты балалары киләчәктә әти-әниләренә караганда авыррак финанс хәлендә калачак дип курка. 2020 елның мартында (коронавирус кризисы башланганда) андыйлар 57 процент булган. Дөньяның икътисади яктан алга киткән 19 илендә (алар арасында Япония, Франция, Италия, Канада, Бөекбритания, Австралия һәм Көньяк Корея да бар) халыкның 70 проценты киләчәк буыннарның матди хәле өметсез дип саный.

Иктисади кризис хакимлек ияләреннән дилбегәне кулда тотып тору өчен интригалар оештыруны таләп итә. АКШта Трамп белән бәйле хәлләр куерды. Элеккеге президентның 2024 елда хакимияткә әйләнеп кайту шансы үсә. Оппонентлары, моны булдырмас өчен, гадәттән тыш адымнар атлыйлар. Экс-президентның Флоридадагы утарында тентү оештырылды. Яшерен мәгълүмат саклаучы 11 комплект документ таптык, диделәр. Андый документлар махсус урыннарда гына сакланырга тиеш икән. Хәзер Трампны шпионлык турындагы законны бозуда гаеплиләр. Реаль төрмә срогы белән яныйлар. Трамп үзен гаепсез дип саный, кәгазьләрне алган урыннарына кире куюны таләп итеп, нәгърә ора. Трампны утыртсалар, илдә гражданнар сугышы башланачак, дип әйтүче белгечләр дә бар.

Американнар тышкы сәясәттә дә ут белән уйнауларын дәвам итә. АКШ конгрессменнары һәм сенаторлары делегациясе янә Тайваньга килде. Пелоси кайтып киткәнгә әле 12 көн генә узган иде. Кытыгына тисә дә, Кытай бу юлы мускуллар уйнатып җавап бирә алмады. Көн саен хәрби өйрәнүләр оештырып торып булмый бит инде.

Европада да рекордлы корылык дәһшәтле кисәтү белән аваз бирде. Континентта елгалар моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә саега. Чехиядә, Нидерландта, Германиядә «ач таш»лар күренә башлады. Урта гасырларда, елга саегып, шул ташлар күренә башласа, бу ачлык көтелүен хәбәр итә торган булган. Эльба елгасындагы шундый ташларның берсенә «Мине күрсәң, ела» дигән язу да уелган. Хәзер бу ташлар күренеп кенә калмыйлар, су астыннан тулысынча чыгып беттеләр. Хәлне соңгы 500 елдагы иң көчле корылык дип бәяләүчеләр бар. Германиядә Рейн елгасы рекордлы дәрәҗәдә саекты. Бу атна башыннан анда кораблар йөзә алмаячак, диләр. Бу Германия икътисадының 0,5 процентка түбәнәюен вәгъдә итә икән.

АКШта да яңа температура рекорды куелды. Континенталь штатларда июль аендагы 17,6 градуслы иң югары төнге температураны теркәделәр. Океаннарны һәм атмосфераны тикшерүче Милли идарәдә моны күзәтүләр алып барган 128 ел эчендә июль ае өчен генә түгел, гомумән, барлык айлар өчен дә иң югары төнге температура дип бәяләделәр.

Россиядә

## ИМПОРТ САЛЫМ БИРМИ

Россиянең Үзәк банкы еллык стратегик документ – бердәм дәүләт акча-кредит сәясәтенең төп юнәлешләре проектын бастырды. Банкирлар 2023–2025 елларга безнең матди хәлгә кагылышлы өч төрле фараз ясыйлар.

Беренчесе – база сценарие. Барысы да шул сценарий буенча барса, ил икътисады 2023 елның урталарына төпкә төшеп җитәчәк һәм шуннан соң акрын гына күтәрелү башланыр дип уйланыла. Оптимистик сценарий икътисадның агымдагы шартларга тиз җайлашуын, бизнесның яңа икътисади элемтәләрне тиз урнаштыруын, параллель импорт нәтиҗәсендә кирәкле җиһазлар һәм товарларның тиешле күләмдә кайтарылуын һәм тиз һәм сыйфатлы үсешкә ирешәчәгебезне гөманлый. Пессимистик сценарий дөнья икътисадының мәтәлчек атып түбәнгә китүен, чималга бәяләр төшүен, алар белән бергә һәм хәтта аларны узып та Россия икътисадының да таудан түбәнгә ыргылачагын күз алдында тота. Мондый очракта, дип саный Үзәк банк, Россия икътисады 2023 елда 2022гә караганда да ныграк түбәнәячәк. Үсеш 2025 елда гына башланыр. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе соңгы җөмләне кирәгеннән артык оптимистик дип саный.

Агымдагы икътисади хәл исә хыялларга бирелмәскә куша. Әйе, әйе, тышкы икътисади элемтәләр арасында сөендерә һәм өметләндерә торганнары бар барлыкка. Вәләкин хәтта рәсми статистика да безне артык туарылып китмәскә чакыра. Финанс министрлыгы мәгълүматлары июль аенда бюджетка импорттан салым керүе 43,7 процентка кимүен күрсәтә. Бу импортка бәйле проблемаларның хәл ителмәвен дәлилли. Аеруча дарулар белән хәл кискен тора. «Дару (аптека) туризмы» чәчәк ата башлады, диләр белгечләр. Россиялеләр, инсулин алырга дип, Казахстанга, антидепрессантлар алырга Грузиягә, Әрмәнстанга, Төркиягә сәяхәт итәләр икән. Мисыр хакимиятләре Россия туристларының илдән күпләп дару ташуына игътибар итә башлаган. Бу аларга бер дә ошамаган, чөнки Мисырда дарулар сыйфатлы, әмма арзан. Арзанлык Нил буенда фармацевтиканың дәүләтнең мул субсидиясеннән файдалануы белән тәэмин ителә. Каһирәдә бу субсидиядән россиялеләрнең файдалана башлавы зур ризасызлык тудырган. Моннан соң күпләп дару җыеп кайтып китүче туристлардан штраф кына түләтеп калмаска, ә аларны контрабандада да гаепләргә дигән фикер өстенлек ала башлаган. Белмәдем дип тә акланып булмаячак, диләр.

Импортның (шул исәптән дарулар импортының да) төп проблемасы акча күчерүгә бәйле. Россия халыкара акча күчерүләр системасы булган SWIFTка тиңдәш булган Россия банкының финанс хәбәрләре тапшыру системасын (СПФС) эшләде. Әмма әлегә дус илләр дә бу системага кушылып китәргә ашыкмый. Россия банк җитәкчелеге үткән атнада СПФСны Һиндстанның банкара түләүләр системасы (SFMS) белән берләштерергә омтылып карады. Тик һинд банкирлары идеяне кире кактылар. Үзләрен Америка санкцияләрен әйләнеп үтүдә гаепләрләр дип куркалар. Түләү белән проблемалар булгач, импорт та проблемалы була инде, нишләтәсең.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Армия-2022» Халыкара хәрби-техник форумында катнашты. Россия Оборона министрлыгы тарафыннан Мәскәү өлкәсендәге «Патриот» үзәгендә узучы чараның ачылу тантанасында катнашучыларны Россия Президенты Владимир Путин сәламләде.

15–21 август көннәрендә узучы форумда ил оборона-сәнәгать комплексының 1,5 меңгә якын предприятиесе 1000нән артык яңа хәрби техника тәкъдим итә. Алар арасында Татарстаннан Казан вертолет заводы, «Ак барс» суднолар төзү корпорациясе, «Ремдизель» АҖ, «Эникс» АҖ һәм башка предприятиеләр дә бар.

Әлеге форум кысасында Рөстәм Миңнеханов Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Денис Мантуров сәнәгать предприятиеләре үсеше мәсьәләләре буенча уздырган киңәшмәдә дә катнашты.

# Үзебезнең тәгәрмәч

**Рәсми хәбәр**

**«Зөя калкулыклары» комплексында Халыкара тарихи техника фестивале узды. «Авторетроклуб-21» оешмасы тарафыннан 15 нче мәртәбә уздырылган чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, әлеге клубның президенты Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.**

Халык үзебездә җитештерелгән тарихи автомобильләр белән күбрәк кызыксына башлады. Югары Ослан районына җыелган машиналарны карап, аларның хуҗалары белән аралашкач, Фәрит Мөхәммәтшин әнә шулай диде. «Үзеңнеке күңелгә һәрвакыт якынрак. Шуңа күрә фестивальгә килгән «Волга», «Москвич» һәм «УАЗ»лар ил өчен горурлык хисләре уята», – диде ул. Аның сүзләренә караганда, әлеге фестиваль белән дә елдан-ел күбрәк кызыксыналар. Быелгы җыенга Мәскәү, Санкт-Петербург, Кемерово, Самара, Саратов, Киров, Пермь, Екатеринбург, Ярославль, Сыктывкар, Чабаксар, Йошкар-Оладан, Таҗикстаннан машина һәм мотоцикллар алып килгәннәр.

– Безнең хәрәкәтнең максаты – илебез автомобиль җитештерү сәнәгате тарихына игътибарны күбрәк җәлеп итү. 16 ел эчендә безнең клуб элеккеге авто һәм мототехниканың кадерен белгән кешеләрне берләштерде, – диде ул, катнашучыларны республика җитәкчелеге һәм авторетроклуб исеменнән сәламләп. – Иске «Победа», «Волга», «Москвич», «ЗИС» һәм «КамАЗ»ларны яңартып, безнең техниканың чит ил маркалары белән көндәшлек итә алганын күрсәтәбез. Технология һәм вакыт мәсьәләсендә бераз калышсак та, үз машиналарыбызны ясый алдык. Бу машиналарны һәм безнең тарихка тугрылык саклый алганыгыз өчен рәхмәт. Бөек Ватан сугышы ветераннары сезгә аеруча рәхмәтле. Сугыш чорындагы машиналарны күргәч, аларның күзләре яшьләнә.

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, бүгенге шартларда үзебезнең автомобильләр һәм технологияләргә ихтыяҗ артачак. Әлеге фестиваль исә тарихны барларга, булганны күрсәтергә мөмкинлек бирә. Ярыш һәм бәйгеләрдән тыш, бу көнне тарихи автомобильләр раллие да узды. Анда катнашучы 28 экипаж Югары Ослан районы һәм Казанны урап кайтты.

# ДӘҮ АБЫЙЛАР БҮЛӘГЕ

**Язарга – каләм, сызарга карандаш бар. Быел «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» акциясе кысасында 1 нче сыйныфка баручы – 7 меңләп, 2–11 сыйныфларда укучы 33 меңнән артык балага букчалар һәм башка кирәк-яраклар тапшырылачак. Әлеге бүләк аз керемле гаиләләрнең хәлен ни дәрәҗәдә җиңеләйтә?**

«ВТ» архивыннан

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, әлеге акция аз керемле, күпбалалы, тәрбиягә алынган, авыру балаларга булышуны күздә тота. Быел шулай ук Луганск һәм Донецк республикаларыннан күченеп килгән 300 бала да читтә калмаячак. Кесә ягы такыррак булган гаиләләрдәге балалар башкалардан ким-хур булып бармас өчен, ел саен иганәчеләр үз өлешләрен кертә, игелек марафоннары уза, шулай бер көнлек хезмәт хакын күчерүчеләр дә бар. Тиеннән күл җыела. 2007–2021 еллар эчендә акция 1 нче сыйныфка баручы 227 мең 270 баланы букчалы иткән. Шулай ук мохтаҗ булган башка гаиләләрнең балалары да нәүмиз калмаган һәм калмый. Бу – барлыгы 306 миллион сумлык ярдәм дигән сүз.

Үзең сатып ала башласаң, барысын да беләсең. Дәү абый-апалар бүләк итә торган портфель һәм кирәк-яракларның бәясе башлангыч сыйныфлар өчен – 4200, уртанчы сыйныфларга – 3000, зурракларга 2800 сумга төшә. Әйтик, пенал – 359, фломастер – 159, гельле каләм – 62,90, пумала – 129 сум. Бу – портфельгә тутырылган кайбер кирәк-яракларның бәясе генә. Исемлек шактый озын.

Әлеге ярдәмне гаиләләр сөенеп аламы, әллә ниндидер читенсенү дә бармы?

– Бүләкне кыенсынып алмыйлар. Бу сорауга фәлсәфи яктан да карап була. Әти-әнинең мәктәпкә әзерләргә мөмкинлеге дә булмау – ул бик үк әйбәт күренеш түгел. Гомумән, безнең дәүләттә андый нәрсә булырга тиеш түгел. Кызганыч, мохтаҗлар да бар шул. Авыр хәлле гаиләләр өчен бик зур ярдәм бу. Бәяләр дә көннән-көн артып тора бит. Әлбәттә, ун меңлек ярдәм булса, тагын да яхшырак булыр иде. Болай 2 мең тирәсе чыга, – ди Балтач районының мәгариф идарәсе башлыгы Ренат Мөхәрләмов.

Балтач районында узачак август киңәшмәсендә 40лап баланы сөендерергә ниятлиләр. Шуның 7се – 1 нче сыйныфка баручылар. Быел районда барлыгы 360 бала беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлый икән. Кайбер эшмәкәрләр балаларга бүләкне тапшырырга өлгергән дә инде. Әйтик, бер кибет хуҗасы 5,5 мең сумлык мәктәп формасы бүләк иткән. Бу ярдәм Балтачта яшәүче Айгөл Шәйдуллина гаиләсенә бирелгән.

– Без дүрт бала тәрбиялибез. Сәмир быел 1 нче сыйныфка бара. Калганнары кечкенә әле. Социаль яклау бүлегеннән, сезгә ярдәм бар, дип шалтыраттылар. Сәмиргә өр-яңа костюм бүләк иттеләр, рәхмәт яугырлары. Сөендек инде. Мөмкинлегебез юк дип, ярдәм сорап йөргән юк. Әлегә ирем генә эшли, шуңа күрә бераз кыенрак, – ди Айгөл Шәйдуллина.

Сәрия МИФТАХОВА

# Яңа дулкын

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ә менә академик Сергей Нетесов фикеренчә, киләсе атнадан Россиядә коронавирус белән чирләүчеләр саны кимергә дә мөмкин.

– Европа белән чагыштырганда, Россиядә чирләүчеләр саны үсеше бер-ике атнага соңрак башланды. Көнбатыш Европадагы авырулар динамикасына караганда, бездә бу чор шушы бер-ике атнада кимүгә таба барырга тиеш, – дигән ул.

Академик әйтүенчә, чирләүчеләр санының артуы ПЦР-тест узу мәшәкатьләренә һәм рәсми рәвештә теркәлмәгән чирләү очракларының күп булуына бәйле. Әйтик, Европаның кайбер илләрендә моны урамда ук – махсус җиһазландырылган палаткаларда эшләргә мөмкин.

**Татарстандагы вазгыять ни хәлдә?**

Хөкүмәт йортында узган «шимбә киңәшмәсе»ндә республикада битлек кию режимын кире кайтару турында сүз булды. Дөрес, әлегә хезмәт коллективларында.

– Эпидемиологик хәлнең үзгәргәнен көтәргә кирәкми. Күмәк иммунитетны алдан кайгырту мөһим. Хезмәт коллективларында, белем бирү оешмаларында һәм социаль тармакның башка оешмаларында эпидемиягә каршы санитар таләпләрне катгый үтәүне тәэмин итәргә кирәк, – диде бу җәһәттән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесе Татарстанда чирләүчеләр саны артуына игътибар итте. Оператив штаб мәгълүматларына караганда, бу күрсәткеч соңгы атнада 32 процент тәшкил итә.

Татарстан Президенты хезмәт коллективларында битлек кию режимын кайтарырга киңәш итте.

– Чирләп киткән кеше хезмәт коллективы, гаилә өчен мәшәкатьләр тудырачак. Хәзер безгә вакцинация һәм барлык санитар таләпләрне үтәү кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сәламәтлекне кайгырту йөзеннән битлек киюнең әһәмияте турында Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының йогышлы авырулар буенча штаттан тыш баш белгече Владимир Чуланов та белдерде.

– Җәмәгать урыннарында битлек киеп йөрергә, сакланырга кирәк. Битлек кию – нәтиҗәле юл, ул респиратор инфекцияләренең таралуын чикли, – ди белгеч.

# 100 МЕҢ ТҮЛИМ, КАЙТАСЫҢМЫ?

**«Авылны үстереп, терелтеп була аны. Тик ул бүген кемгә кирәк? Эше бар – кешесе юк, акча түләп була – белгече юк». Аксубай районының Яңа Ибрай авылында яшәүче тәҗрибәле фермер Ильяс Сөләймановның җан авазы белән әйтелгән сүзләре бу. Яшьтән үк терлек арасында булган, тынгысыз хезмәтнең бар авырлыгын һәм рәхәтен үз җилкәсендә татыган фермер белән фермерлык, авыл һәм аның киләчәге турында сөйләштек.**

2010 елда ул, «Гаилә фермасы» программасына кереп, беренче фермасын төзегән. Узган ел тагын бер грант отып, яңасын сафка бастырган.

– Алабугада алты ел эшләп кайтканнан соң ныклап торып фермерлык белән шөгыльләнә башларга булдым. Эшемне бер баш сыердан һәм 50 сутый җирдән башлаган идем. Бүген 200 башка якын терлегем һәм 368 гектар җирем бар. Терлекләрнең 150се – савым сыеры, – ди ул.

Кама аръягы зонасында беренчеләрдән булып фермасын роботлаштыручы да әле Ильяс абый. Бүген аның 150 сыерын ике робот сава.

– Бу сыер савучы таба алмыйча җәфаланудан килеп чыккан карар булды. Безнең эштә иң авыры – эшче куллар табу. Бүген 100 мең сум хезмәт хакы бирәм дисәң дә, авылга сыер саварга килүче юк. Менә син кайтыр идеңме?

Мин, «юк» дигәнне аңлатып, баш чайкадым.

– Кайтмыйсың шул. Кызым да шулай ди. Бүген – шулай, ә иртәгә бөтенләй булмаячак. Шуңа күрә ике робот алырга булдым да инде. Авылларга эш, акча булмаганлыктан кайтырга теләмиләр, диләр. Эш анда түгел. Тырыш кешегә эше дә, акчасы да бар. Хәтта шәһәрдә дә аерым бер һөнәрләргә кеше таба алмыйлар. Кая китә ул халык? Шуңа шаккатам мин. Аптырагач, ике ел үзбәкләрдән саудырдым сыерларны.

Сыерларны роботлар сава башлагач, беренчедән, кадрлар кытлыгы кимегән. Икенчедән, сөт күләме арткан.

– Робот сава башлагач, сыерларның продуктивлыгы 3 атнада 6 литрга күтәрелде. Шул ук карау, шул ук ашату югыйсә. Чөнки роботлар дөрес сава. Көненә өч тапкыр, дөрес технология белән эшли бит ул, – диде Ильяс Сөләйманов.

Фермер әйтүенчә, замана машинасы сөтлебикәләрне җиде сәгатькә бер тапкыр, хәтта төнлә дә сава. Ашарга дип кергән сыерны машина савып чыгара. Вакыты җитмәсә, кире чыгарып җибәрә. Арада тәүлегенә 40 литр сөт бирә торган сыерлар да бар.

Хәзер фермада Ильяс абыйга бер генә кеше ярдәм итә.

– Барысына да үзем өлгерү мөмкин түгел. Шуңа күрә тагын бер белгеч эзләгән идем. Техниканы, компьютерны белә торган мал табибы булса, яхшы булыр иде, дип теләдем. 100 мең сум хезмәт хакы түләргә дә риза идем. Авылда шундый кеше таба алмыйм. Киләчәге бармы авылның? Кызганыч. Үземә зур булмаган сөт заводы төзисе килгән иде. Ләкин әлеге дә баягы эшләрлек кеше булмагач, бу уемнан да кире кайттым. Авылны үстереп, гөрләтеп яшәтеп була аны. Тик ул инде хәзер беркемгә дә кирәкми. Эшли торганы китеп беткән, калганы андый эшне булдыра алмый. Ветеринария хезмәте дә бик аксый әле бездә, – дип ачынып сөйләде тәҗрибәле фермер.

Фермер сөтне сөт заводына тапшыра. Бүген аның өчен литрына 31 сум түлиләр.

– Июльдә 1,5 сумга киметтеләр сөт бәясен. Югыйсә бер сәбәп тә юк. Сөт бәясе төшү беренче чиратта аны эшкәртүчеләргә бәйле. Башка елларны майда ук төшереп куялар иде. Быел шулай да бәяләр тотрыклы торды әле. Хәзер инде сөт күләме дә кимеде. Узган ел, азык җитәрлек булмау сәбәпле, бер типлы азык ашата алмадым. Шул сәбәпле сөт кимеде. Югыйсә минем сыерларның сөтләре төшәргә тиеш түгел иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, җәен фермерга балалары да булыша. Каникул вакытында ике улы – әтиләренең уң кулы.

– Улларымның берсе аграр юнәлешне сайлады, икенчесе – электр энергиясе буенча белгеч. Карарларында нык торып, кире авылга кайтырлар, дип өметләнәм, чөнки бөтен булдырганым, тапкан-тырышканым алар өчен. Барысын да аларга кала дип төзедем. Тик алар да вакытвакыт: «Әти, монда эш бетә торган түгел икән», – диләр. Җәен бер минут тик торганнары юк. Иртәдән алып төнгә кадәр аяк өстендә. Менә хәзер бодай сугарга керештек, – ди ул.

Шулай да фермерлык үз-үзен аклыймы? Әлеге сорауга Ильяс Сөйләйманов менә ничек дип җавап бирде:

– Аклый, ләкин авыр. Бу – бары тик безнең хезмәт белән генә бара торган эш. Бүген эшлисе эшне иртәгәгә калдырып булмый. Көне-төне эшләргә кирәк, бер нәрсәне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Ә без – инде яшьтән эшләп, чыныгып үскән егетләр. Менә балаларыбыз безнең эздән ахыргача барырга риза булырмы – анысы билгесез. Чөнки алар инде үскән вакытта ук монда җиде кат тир чыгарасын белеп, күреп үсә. Киләчәктә терлек азыгы сала торган машина ала алсам, механизаторларга да ихтыяҗ булмас иде. Бәлки кайчан да булса бездә дә фермерлар, чит илнекеләр шикелле, фермаларын өчәр көнгә калдырып, ял итәргә китә алырлар иде… Тик бездә аңа кадәр бик ерак әле.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Мин кулыма китап алам

# ДӨНЬЯНЫ ЯУЛАУ ӨЧЕН...

**Әдәбият турында сүз чыкса, безнең кайберләребез кызыбрак китә дә дөнья әдәбияты турында сүз куерта башлый һәм дөньяны яулау турындагы хыялга бирелеп ташлый. Дөньяны яулау – әйбәт нәрсә, әлбәттә. Һәр солдат кесәсендә генерал погоны ятарга тиеш. Тик мин елмаебрак куярга мәҗбүр булам. Андый уйлар бераз сәеррәк булып тоела. Башта үз халкыңны яуларга, үз укучыларыңны табарга кирәк.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Китапны укучыларга җиткерү юллары турында без аз гына соңрак сөйләшербез. Ә әлегә... Укучыларны җәлеп итү өчен иң беренче чиратта нәрсә кирәк? Яхшы әсәр, әлбәттә. Ә әсәр яхшы булсын өчен, талантлы һәм оста язучы кирәк.

Талант Ходайдан бирелә дип әйтәләр инде. Бәлки, чынлап та шулайдыр. Без яшь чакта әдәбият мәйданына зур гына төркем булып килгән идек. Ләкин тора-бара өч-дүрт кеше генә калдык. Кемнәрдер башка шөгыльгә күчеп китте, кемнәрдер сирәк-саяк кына яза башлады. Үз талантының авырлыгын күтәрә алмыйча харап булучылар да очрады. Талант ул корал шикелле бит инде, зур талантны уйната, һич югы күтәрә алу өчен шәхеснең дә зур һәм көчле булуы кирәк. Талантың ачылсын, осталыгың артсын өчен дә даими рәвештә язу, өйрәнү, камилләшү таләп ителә. Хәзерге чорда бу бик авыр да түгел. Әдәби осталыкны арттыру өчен китаплар, вебинарлар, онлайн мәктәпләр бар. Инглиз телендә алар бигрәк күп, кайберләрен Дэн Браун һ. б. танылган язучылар алып бара. Русчага тәрҗемә ителгәннәре дә хәтсез генә. Русларда Дарья Донцова, Сергей Лукьяненко кебек язучылар алып барган дәресләр дә бар. Әдәбиятка багышланган сайтлар бихисап. Гомумән, осталыгын арттырырга теләгән язучы өчен мәгълүмат кытлыгы юк. Татар телендә генә мондый нәрсәләрне күргәнем булмады. Бер карасаң, идея, сюжет, композиция кебек нәрсәләр кайсы әдәбиятта да бер үк төрле инде. Ә менә тел-сурәтләү чаралары алай түгел, һәр әдәбиятның – үз теле. Бәлки, татар телендә дә шундый чаралар, әдәбиятның төрле өлкәләренә кагылышлы дәресләр оештырырга кирәктер. Яшь язучылар өчен инде. Ә бәлки, андый мохтаҗлык бик юктыр да. Үсәргә, камилләшергә теләгән кеше үзенә кирәкле мәгълүматны әллә кайлардан эзләп таба ул.

Әсәр яхшы булырга тиешлеген бөтен кеше дә белә инде. Тик нинди әсәрнең әйбәт, ниндиенең начар икәнен генә берәү дә белми. Монда мәсьәләне язучының осталыгы, әсәрнең камиллеге түгел, ә укучының карашы хәл итә бугай. Бу үзе үк бик күп нәрсәләргә бәйле. Әйтик, бишенче сыйныф укучысына минем «Сары йортлар сере» повестен тоттырсаң, ул аның бернәрсәсен дә аңламаячак. Шуңа охшашрак хәл булган да инде. Бер авыл китапханәчесе өлкән яшьтәге ханымга минем «Китап» романын биреп җибәргән. Теге ханым икенче көнне үк аны кире китергән: «Берүк мондый нәрсәне миңа бүтән бирә күрмә!» Начар роман түгел инде ул, бик яратып, кулдан кулга йөртеп укучылар да булган. Ләкин һәр яшьнең – үз әдәбияты. Китап укучының ничә яшьтә булуы үз эшен эшли. Алай гына да түгел, аның нинди катлау кешесе икәнен, белем дәрәҗәсен, һөнәрен, нәрсә белән кызыксынуын да искә алырга кирәк. Нинди җенестән булуын да, әлбәттә. Менә монда инде маркетинг өлкәсендә сегментация дип аталган күренешкә килеп төртеләбез. Бу язучының үзеннән бигрәк китап сәүдәсенә кагыла инде һәм, үзебезчә әйтсәк, кемгә нинди китап тәкъдим итәргә икәнен ачыклау була. Базарда күлмәк кенә сайлаганда да шулай бит инде, һәркемнең – үз яше, үз зәвыгы, үз үлчәме, гәүдә төзелеше. Холыксызрак иргә хатын-кызлар күлмәге яки колготки тәкъдим итсәң, кыйнап та китәргә мөмкин.

«Китап укучы» дию ул – гомум нәрсә. Китап укучылар да әллә ничә төркемгә бүленә: кемдер документаль әсәрләр, кухня серләре, дару үләннәре, һ.б. нәрсәләр белән кызыксына, кемдер әдәби китапка тартыла. Ләкин әдәби китап та бертөрле генә булмый. Ким дигәндә дә жанрларга бүленә. Детектив, фантастика, мистика, фэнтези, тарихи әсәр, мәхәббәт романы һ.б. Бөтенесен дә укып баручылар бар, әлбәттә. Аерым бер жанрны гына үз итүчеләр дә күп. Монда инде укучыларның зәвыгын өйрәнү һәм жанрлар төрлелегенә омтылу таләп ителә. Нәшриятлар һәм китап сатучылар эше инде монысы. Ләкин автор да үзенең кемнәр өчен язуын бераз чамаларга тиештер.

**ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫННАН АВГУСТ АЕНДА ИҢ ПОПУЛЯР КИТАПЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

**Классиклар**
Габдулла Тукай «Шүрәле» һәм «Су анасы»
Муса Җәлил «Моабит дәфтәрләре»
Фәнис Яруллин «Киек каз юлларыннан»
Габдрахман Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»
**Тарихи һәм фәнни-популяр басмалар**
«Татар милли кухнясы» һәм «Татар дөньясы» альбомнары
«Иделдә Болгар цивилизациясе», «Урта гасырларда татарлар ничек яшәгән / Урта гасырларда татарлар ничек яшәгән: көнкүреш тарихы» тарихи басмалары
«Татар халык әйтемнәре»
**Балалар өчен китаплар**
Абдулла Алиш «Әкиятләр»
«Бизнес», «Песиләр һәм песи балалары», «Су асты дөньясы», «Этләр» энциклопедияләре
«Татар халык әкиятләре»
«Идел буе халыклары әкиятләре»
«Рәсемле татарча-русча тематик сүзлек» (Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова)
«Чебиләр зарядкасы»
**Заманча авторлар**
Ольга Иванова «Гәүһәршад» һәм «Сөембикә»
Марат Кәбиров «Яралы моң» (шигырьләр)
Айгөл Әхмәтгалиева «Туташ»
Галимҗан Гыйльманов «Албастылар»
Рәфкать Кәрами «Йөрәгемне ут алган»
Вакыйф Нуруллин «Әгәр син булмасаң»

Әдәбият популяр булсын өчен, һәр әсәр үз вакытында чыгарга тиештер. Без әле аңа ирешә алмадык. Нәшриятка биргән кулъязмалар ким дигәндә дә берике ел чират көтеп ята. Бүгенге тизлек заманында бу вакыт эчендә әсәр үзенең актуальлеген югалтырга да мөмкин. Журналистикада «кайнар яңалык» дигәнрәк төшенчә бар бит әле... Менә шуның шикелле үк әдәби әсәрләр дә заман белән бергә атларга, бүгенге чорга аваздаш булырга тиештер кебек тоела. Мәңгелек әсәрләр язу мөмкинлегенә мин бик ышанып җитмим. Үз дәвереңдә дә популяр була алмагансың икән, киләчәк чорга син ни пычагыма кирәк инде, аларның үз язучылары туачак.

Бу проблемадыр инде, тик монда электрон китаплар ярдәмгә килә ала. Минем 175 нче мәктәп вакыйгалары тәэсирендә язылган «Тик син генә...» дип аталган повесть бар. Үземнең MaratKabirov.com сайтында да, Литреста да сатыла ул. Иң күп укылучы, иң үтемле китапларның берсе. Мин аның төп сәбәбен әсәрнең әйтеп бетергесез дәрәҗәдә камил булуыннан түгел, ә нәкъ үз вакытында үз укучысына тәкъдим ителүендәдер дип уйлыйм. Бездә әдәби әсәрне «рухи азык» дип тә әйтәләр бит инде. Һәр азык «свежий» чагында, кайберләре хәтта суынып өлгергәнче, кайнар килеш тәкъдим ителергә тиеш.

Китапның яхшы булуы да, үз вакытында чыгуы да бернәрсә әле, аның укучыга барып җитүе мөһим. Монысы – иң мөһиме! Кеше аракы эзләп тә, тәмәкесе бетсә дә, төн уртасында кибетләргә чыгып китәргә мөмкин. Ашарына икмәге булмаса да шулай. Ләкин беркем дә китап эзләп чыгып йөгерми. Ул һәрвакыт кешенең күз алдында торырга тиеш. Мин менә хастаханәләрдә, вокзалларда китап кибете булмауга гаҗәпләнәм. Иң үтемле урыны шул бит инде аның.

Мин авылда яшим инде соңгы арада. Зур, затлы авыл. Кибетеннән бөтен нәрсәне дә табарга була. Анда тик китаплар гына юк. Авылларда гына түгел, район үзәкләрендә дә шундыйрак хәл. Башкортстанда, мәсәлән, миллион ярым татар яши, ә Уфада татар китаплары сатыла торган кибет юк. Элек бар иде ул автовокзал янында, без шунда барып төянеп кайта торган идек. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә китап кибетләре булса, укучылары да табылыр, артыр иде кебек.

Бер сүз белән әйткәндә, хәзер безнең китап сату системасы җимерек хәлдә. Кайчагында моны махсус эшлиләрдер, халыкны китаптан биздерергә тырышалардыр кебек тә тоелып китә. Алай түгелдер инде ул. Без аңлап җиткерә алмаган бүтән сәбәпләре бардыр.

«Керем китерми», – диючеләр дә бар. Монысына мин бик ышанып җитмим инде. Җаен белеп, әйбәтләп тәкъдим итмәсәң, арзан бәягә куелган алтыныңны да сата алмый утырырга мөмкин. Эш монда язучыда да, китапның сыйфатында да түгел, ә сәүдә итә белмәүдә, сатучыларның наданлыгындадыр. Әлбәттә, бөтен нәрсә дә тиз генә табыш китермәскә дә мөмкин. Китап бит ул нефть тә, газ да түгел. Ләкин базарны өйрәнергә, укучыларны җәлеп итәргә буладыр инде. Ботинка шнурыннан беләзек ясап, аны талисман дип, фәлән меңгә сатып ятучылар да бар бит. Хәтта табыш китермәгән очракта да бу телебезне, мәдәниятебезне, милли үзенчәлегебезне саклауның бер ысулы лабаса. Милләтнең киләчәгенә инвестиция дип әйтергә дә була.

Бөтен дөньяны яулау турында сөйләнсәк тә, безнең үз дөньябыз шушында бит инде. Татар дөньясы. Башта шуны яуларга, аякка бастырырга кирәк.

Марат КӘБИРОВ

# КӨННӘР КӨЗГӘ АВЫШКАНДА

**Авыл сулышы**

**Белеп җырлый Салават: «Әле генә кергән идек шау чәчәкле майларга...» Көннәрнең бер-бер артлы үткәнен, җәйләрдән көзгә күчеп баруыбызны сизми дә калабыз шул. Соңгы көннәрдәге һава торышы җәйге челләне хәтерләтсә дә, табигатьтә әле һаман матур, җәйге көннәр дип ышандырырга тырышса да...**

Без генә түгел, басу-кырлар да сизә инде көзгә авышканны. Язы-җәе соңга калып килде дисәк тә, соңгы көннәрдәге тоташ коры эссе көннәр, шактый юмарт кыздырган кояш барысын үз урынына куйды: елдагыдан бик аз гына соңарып өлгерде кырлар. Анда инде киеренке эш бара. Көзнең якынлыгын искәртеп, сап-сары иген кырлары башта камылгача бушап кала, алар артыннан җирләр эшкәртелеп, әлеге караңгы төсләр күңелгә көзге моңсулыкны бирә. Ни сәбәпледер, язын эшкәртелгән җирләрдән аерыла алар. Юкса шул ук җир, шул ук туфрак...

Авылда көз исе инде. Көзнең билгеләре һәркайда үзен сиздерә. Календарьда август уртасы гына бит әле, нинди көз, дияргә ашыкмагыз. Бәлки, калада бу күчеш чоры сизелмидер, ни дисәң дә, әле яфракларга сары төшмәгән... Хәер, авылда да агач-үләннәр төсен салса да, быел әле саргаерга ашыкмый кебек. Алай гынамы, күптән түгел Балтачта берәүләрнең алмагачы кабат чәчәк аткан, дип социаль челтәрдә фото куйдылар әнә. Алмалар арасында ап-ак чәчәкләр! Табигать тә саташкандыр, чалт аяз күккә, җылы көннәргә өметләнгәндер. Тик хикмәт билгеләрдә генә дә түгел, ә сала кешесенең күңелендә, ахрысы. «Кичәге кич күңелгә моң салды. Кинәт салкынаеп киткән кич, көздә генә була торган ачы сагыш күңелне кисеп кенә ала торган тойгыны уятты. «Җәй тәмамлана бит» дигән уй йөрәкне сыздырып узды. Юк әле, җәй бетмәгән. Июль азагы гына! Көзләргә ерак әле, дип шатландым», – дип язган иде инде моннан унбиш көнләп элек бер танышым үзенең «ВКонтакте»дагы битенә.

Нигәдер бала чактан ук күңелгә керә иде ул августтагы моңсулык. Җәйге каникул бетеп килгәннән туган моңсулык кына булмагандыр ул, чөнки мәктәпне гомерем буе яраттым. Көз дә иң яраткан ел фасылым иде. Әле көзнең дә яңгырлысын, елагын ярата идем. Бу моңсулык әлегәчә, күпме еллар үтсә дә, һаман кабатлана: аны сизми, тоймый, күрми калып та булмый. Һавага да, агач-үләннәргә дә, агымсу өстенә дә сарыла ул. Таңнар да, кичләр дә башкача була бу чорда. Бигрәк тә кояш баер алдыннан арта әлеге моң. Табигатьтә андый моңсулык фәкать карлар эреп беткәндә генә кабатлана. Җирләр ачыла гына башлаган вакыт. Бар җирдән дымлы, моңсу һава бөркелә. Күңелне мөлдерәмә тутыра торган чор ул да. Мин генә түгел, язгы һәм көзге моң турында башка кешеләрдән дә еш ишетергә туры килә.

Авылда көз исе, дигән идем. Хәер, биредә һәр ел фасылының үз исе бар. Шәһәрдә дә шулай инде ул, димәгез. Юк, шәһәрдәгедән үзгә исләр ул. Әйтик, язын эшкәртелгән җирләрдән чыккан исне каланыкылар ничек белә, каян исни алсын?! Көннәр көзгә авышкан бу чорда да бар андый ис. Алма исе дип уйлаучылар ялгыша. Ындыр табакларында көн-төн эшләгән ашлык киптергечләрдән таралган ис бу. Бигрәк тә иртән һәм кичен урамга чыксаң, кичке тынлыкта аларның бер көйгә эшләп утырган тавышы күрше авылдан ук ишетелә һәм ашлык исе дә безгә кадәр тарала. Бу ис һәм бу тавыш та шатлык-сөенеч түгел, нигәдер күңелгә моңсулык бирә.

Шушы вакыт җитсә, авыл кешесе инде күңеле белән көзге эшләрне барлый башлый. Көзге эшләрне генәме икән? Кемнәрдер әле бу көннәрдә икенче кат печәннәрен җыя, тик бу инде теге чактагы печән вакыты түгел, ул инде соңга калган эшләрне үтәү, өстән бурыч төшерү кебек кенә тоела. Җәй никадәр иртә килсә, соң китсә дә, барыбер җитми ул. Ел саен планлаштырган дөнья кадәр эшләр өелеп кала. Җәен яңгырлы көннәрдә эшләп булмый торган, эссе, аяз көннәрдә эшләргә авыр булган яки эшлисе килмәгән эшләр дә була. Августның икенче яртысы инде ул бу яктан ниндидер өмет, соңгы мөмкинлек тә бирә кебек. Җәй озын әле, эшләрбез дигән эшләрне башкача күчереп булмый. Иртә язда бу җәйгә күпме план корасың, әллә ниләр эшләрсең кебек тоела. Тик эшли алмаган эшләр яки бара алмый калган җирләр турында үкенечләр ел да табыла. Сентябрьгә бик өметләнеп тә булмый, аның ничек киләсен белеп булмый. Исән-имин бәрәңгеләрне казып алып урнаштырсаң, өченче катка печән басуларын җыештырып тәртипләсәң, бакчаларны кышкы әзерли алсаң да шөкер итәрлек кенә була.

Әмма телибезме-теләмибезме, без әзерме-юкмы, табигатьнең – үз кануннары. Исәп инде көнләп-сәгатьләп көз файдасына эшли. Ул ашыгамы, без акрынрак кыймылдыйбызмы – белгән юк. Вакыт агышына һич тә ияреп өлгереп булмый. Инде кемнәрдер, бәрәңгене казып алдык, дип сөенә. Бәлки ул иртә өлгерә торган сорттыр, тик күңел әле бу эшкә әзер түгел. Ашыгалар, ашыктыралар, дип уйланасың. Гомер-гомергә безнең авылныкылар тирә-якта иң беренче булып бәрәңге казырга чыга иде. Хәзер инде бездән өлгеррәкләр күп. Хәер, бакчалар үзләре әйтә, өйрәтә инде кайчан эшлисе икәнне. Вакыты җиткәч, алар үзеннән-үзе җыюны, тәртипләүне сорый. Бүген инде, чыгып, чүп утыйсы килми: чүп вакыты үткән, дип уйлыйсың, бәрәңге бакчаларының да өскә чыккан алабута-билчәннәрен генә җыясың. Язын иң беренче утаган чүпләрнең тәме (ни дисәң дә, кыш буена чүп утау да сагындыра), бакчаларның матурлыгы да башка кабатланмый. Көзен уңышы җыеп алынгач та, бакчага үзенчә, үзгә ямь керә. Җирләрен эшкәртеп, агач-куакларын бәйләп кергәндә мин ел да: «Язга кадәр!» – диеп саубуллашам. Көзләргә кереп барганда да инде күңел якты, матур язларны сагына башлый. Алда әле караңгы көзләр, салкын кышлар, дип күңелнең бер почмагы сулкылдый. Көзнең алтынга күмелгән матур чакларын, кышның ак, саф карларын исеңә төшер, ди аңа икенче бер почмагы. Җаннар тыныч булсын, имин көзләр килсен, дип теләргә генә кала...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

# 45КӘ КАДӘР ЯРЫЙ

## БЫЕЛГЫ «БЕЗНЕҢ ЗАМАН» ФЕСТИВАЛЕНДӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР БАР

Безнең яшьләр, дисеннәр! «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләрнең иҗат фестиваленә гаризалар кабул ителә башлады. Бу хакта фестивальгә багышланган матбугат очрашуында хәбәр иттеләр. Быел ул 10 нчы мәртәбә уздырыла. Кечкенә юбилей уңаеннан катнашучыларның яшен 18дән алып 45кә кадәр дип билгеләгәннәр.

Сәбәбе гади: алдагы елларда катнашучыларның үтенече бу. 35нең теге ягына чыккannар, җитми калды бит, дигән.

– Юбилей елы булгач, рөхсәт бирәбез. Шуңа да быел катнашучыларның саны тагын да артыр дип уйлыйм, – дип аңлатты Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Родион Карпов. – Әлеге фестиваль иҗади яшьләрне барлап кына калмыйча, аларны төрле яклап үстерергә, тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итә. Шулай ук яңа буын кадрлар тәрбияләүгә дә зур өлеш кертә ул. Шушы ун ел эчендә барлыгы меңнән артык оешмадан 8 меңләп кеше катнашты.

Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Һашимова сүзләренә караганда, ул елдан-ел үсә, камилләшә.

– Нинди генә һөнәр иясен алсаң да, аның күңелендә моң яши. Берәүләр – җырга, берәүләр биюгә сәләтле. Әлеге фестиваль нәкъ менә шундый: эштә дә, иҗатта да матур үрнәк күрсәтүче яшьләрне барлый, аларны тагын да үстерә. Катнашучыларга, аларның гаиләләренә бик зур рәхмәт әйтәсем килә, – диде ул.

Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов исә фестивальне гади бер чара гына түгел, зур бер хәрәкәт дип атады.

– Эшче яшьләр өчен гаять әһәмиятле хәрәкәт ул. Аның турында безнең республикада гына түгел, бөтен дөньяда беләләр. Кешегә, үзен бәхетле итеп тояр өчен, яраткан гаиләсе, яраткан эше һәм яраткан шөгыле кирәк. Иҗатка мөкиббән яшьләр өчен безнең фестиваль үзләрен чын мәгънәсендә бәхетле хис итәргә ярдәм итә. Дөресен генә әйткәндә, тамашачы залыннан карап утырганда, алдыңда, әйтик, ЮХИДИ хезмәткәре, йә булмаса эретеп ябыштыручы, инженер чыгыш ясавына ышанмыйсың да, – дип сөйләде ул.

Фестиваль-бәйгегә гаризалар 15 сентябрьгә кадәр кабул ителә. Бу хакта фестивальнең генераль продюсеры Дмитрий Туманов әйтте.

– Төп приз – 500 мең сум. Ләкин эш акчада түгел, һәм безнең яшьләр моны яхшы аңлый. «Безнең заман»да татулык, мәхәббәт, ә иң мөһиме – дуслык хөкем сөрә. Әйтик, Түбән Камада яшәүче берәү фестивальдә Яшел Үзәндә яшәүче белән таныша да, шуннан алар бәйрәм саен бер-берсенә кунакка йөрешә. Шәп бит? Бүгенге заманның төп проблемасы ул – ялгызлык. Ә монда син ялгыз түгел, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

2020 елда фестивальдә катнашучыларның саны **900**ләп булса, узган ел **1300** кеше катнашкан. Оештыручылар быел бу сан тагын да артыр дип өметләнә.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексы үсешенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ВАТАН агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры **Әхмәтов** Мансур Готыф улы; күп еллар дәвамында нәтиҗәле эшләве һәм хезмәтендә ирешкән уңышлары өчен шәхси эшкуар **Кашаева** Фәүзия Хәсән кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары **Кропотова** Наталия Анатольевна; республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең урманчылык һәм урман культуралары кафедрасы профессоры **Мусин** Харис Гайнетдин улы; мәгариф системасын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Чаллы технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри мәгариф учреждениесе директоры **Суворов** Виктор Семенович; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасында баскетболны популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен Казан шәһәренең «Уникс баскетбол клубы» җирле иҗтимагый оешмасы генераль директоры урынбасары **Фәрәхетдинов** Салават Гали улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең курчак уйнатучы артисты **Безус** Рәмзия Мәхмүт кызы; «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Корнишина** Татьяна Михайловна; һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге рәисе урынбасары **Васильева** Татьяна Юрьевна; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Уникс баскетбол клубы» Казан шәһәре җирле иҗтимагый оешмасының техник бүлеге башлыгы урынбасары **Данилов** Сергей Викторович; Казан шәһәренең «Ракета» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Дружков** Сергей Геннадьевич; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен хезмәт ветераны **Димиев** Риф Шәйсолтан улы; кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының кадрлар бүлеге әйдәүче белгече **Нәҗметдинова** Резеда Язкәр кызы; Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе дәүләт хезмәте, кадрлар, социаль яклау һәм судьялар берлеге органнары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы **Насыйбуллина** Гөлия Вәкил кызы; мәдәният һәм сәнгать үсешенә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казан шәһәренең «5 номерлы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Сөләйманова** Светлана Рафаэль кызы; музыка сәнгате үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Әлки районы мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе концертмейстеры **Шиһапов** Ринас Баһман улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Сабиров** Наил Закир улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Шушы көннәрдә якташыбыз, Татарстанның халык артисты **Илсур САФИН** үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Хөрмәтле Илсур Кәрибулла улы! Әле сиңа бу яшьне биреп тә булмый. Егет чагың гына әле үзеңнең! Педагог буларак, күпме яшьләргә белем бирәсең син. Без, горурланып, Илсурның сәхнәдә үз урыны, үз моңы, үз җыры бар, дип әйтә алабыз! Аның кебек ватан, туган як, сугышка кагылган көйләрне тамчысына кадәр тамашачы күңеленә җиткерүче бармы икән тагын? Без якташыбыз белән бик горурланабыз. Киләчәктә дә моң чишмәсенең саекмавын, сәламәтлекнең ныгын, гомернең озынын телибез. Гомер үтә дип моңайма да, син үткән юллар күпләргә үрнәк һәм маяк ул! Матур тормыш, җан тынычлыгы, бәхетле көннәреңнең күп булуын, борчу-хәсрәтсез яшәвеңне телибез.

Ихтирам белән, Казандагы «Апас» якташлар җәмгыяте


Яшәеш

# *Бар осталыгы – бер кулда*

Тимаевларның гаилә архивыннан

Баулы районының Исергәп авылында яшәүче Тимаевларның ишегалды балалар бакчасын хәтерләтә. Монда тәгәрмәчтән ясалган пар аккошлар да, мичкә кочаклаган аюлар да, крокодиллар да бар. Җил тегермәне, кое да – аның хезмәте. Боларны ул бары бер кулы белән эшләгән.

18 яшьлек чагында фермада терлекләргә бәрәңге пешерү җайланмасы ясаганда өзелгән аның биш бармагы. Ташмазар тыгылды бугай дип, техниканы сүндереп, гаебен эзләмәкче булган, тик хезмәттәше ялгыш кабызып җибәргән.

Башта ничек яшәрмен, дип борчылса да, тора-бара үзен ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнгән. Күрәсе сынау булгандыр, дип тынычланган. Хезмәттәшенә дә ачу сакламый.

Әмма эшсез утырмый ул. Трактор да йөрткән, фермада силосын, сенажын төягән. «Ике куллы кешеләр бер йөк төягәндә, мин дә алардан калышмадым. Алар белән беррәттән эшли идем. Бер дә аптырап тормадым. Өйдә унар баш мал асрый идек әле. Хәзер сыерларны бетердек», – ди 63 яшьлек Ирек абый. Нәрсәдер барып чыкмаса, киресенчә, ник кулыңны кирәкмәгән җиргә тыктың соң, дип сүгеп тә ала икән.

Шушы авыл кызы Гөлшат белән гаилә корып, өч ул үстергәннәр. Тик 7 яшьлек сабыйлары суга батып үлгән. Авырлыклар бу гаиләне аз сынамаган. Йөрәгенә операция дә кичергән Ирек абый. Тормыш иптәше белән бер-берен-не аңлап яшәгәндә, оныклары: «Бабай, сиңа ничек ярдәм итәргә?» – дип торганда, моңаерга вакыты юк гаилә башлыгының. Кирәк икән, ул җырлап җибәрә. Сәхнәләрдән дә төшмәгән, авылның беренче егете булган.

Агач эшенә тартылу исә оныгы Ранэль тугач башланган. Башта ул аңа караватъ, аннан бишек ясаган. Әкренләп уенчыклар, машиналарга да чират җиткән. Башка оныклары, бакчага йөри башлагач та, эш кушып кына торганнар үзенә. «Бабай, безнең бакчага сыерчыкларга оя, җимлекләр кирәк», – дип заказ биргәннәр. Каршы килеп буламыни? Төрле әкият геройлары, җәнлек образлары әнә шулай туган. Күптән түгел бакчага бүләк булсын дип, агачтан кое ясап биргән. Гөлшат ханым үзе дә тәрбияче ярдәмчесе булып эшләгән икән. Бу көннәрдә остага Казаннан ук заказлар килгән әле. «ВКонтакте»дагы сәхифәсеннән күреп, кечкенә сандыклар ясарга кушкан шәһәр ханымнары. Хезмәтләре арасында чана, тарантас, җил тегермәннәре, өстәл-урындыклар да бар.

– Моның кадәр тәгәрмәчне каян алып бетерәсез? – дип сорыйм аннан.

– Күршедә генә автосервис. Килеп алып кит, дип кенә торалар. Кытлык юк, – ди Ирек абый.

Пар аккошларны көнгә берничәне ясый алса, крокодил өчен вакыт күбрәк китә. Ни өчен дигәндә, тешләрен, аякларын ясыйсы. Тутый кошлар да ишегалдын бизи. Тәгәрмәчле техникалар да күренә.

Иртүк торуга, остаханәсенә чыгып, 3–4 сәгать шунда кайнаша. Кайбер көнне агач эше белән мавыгып китеп, төшке ашын да оныта. Ниндидер планнар корып яшәми, башына идея килү белән, тизрәк тормышка ашыру ягын карый. Ашыгып эшли торган гадәте дә юк. Чүкеч тотканда гына протез кия, ә болай барысын да сул кулы белән башкара.

Хезмәте өчен акча сорап алмый. «Эшли беләсең, сата белмисең», – дип сүгәләр икән аны. Күңел хакы өчен дип тырыша. Эшләгәч, азмы-күпме акчасы да керә.

Сау-сәламәт булып та, тормыштан зарланучылар, эшләргә яратмаучылар бар. Ирек абый әйтүенчә, теләк кирәк, мәҗбүриләп бернигә ирешеп тә булмый. «Тормышымның мәгънәсе бар. Шуңа күрә күңел матурлыкка омтыла. Мин бит аны үзем тудыра алам», – ди сынауларга бирешмәүче Ирек Тимаев.

Сәрия МИФТАХОВА

# ТАРИХИ ВАКЫЙГА

## ИЗГЕ БОЛГАР ҖИРЕНДӘ «КАРА ПУЛАТ» ОПЕРАСЫН КҮРСӘТТЕЛӘР

«Татар-информ»

**12–13 августта Болгар музей-тыюлыгында «Кара пулат» операсы куелды. Ул сәхнәдә түгел, ә Болгарда XIV гасыр урталарында төзелгән бина – Кара пулат фонында күрсәтелде. Ачык һавада куелган беренче татар операсын без дә карап кайттык.**

Операның премьерасы 2015 елда Тинчурин театрында булган иде. Ул Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды ярдәмендә куелды. Әсәрнең кабаттан тамашачыга тәкъдим ителүе Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган.

Операны тамаша кылырга Минтимер Шәймиев тә килгән иде.

– Кыска гына вакыт эчендә гасырлар дәвамында килгән хыялыбызны тормышка ашырдык. Бүген без «Кара пулат» тарихи операсын карарга җыелдык. Бу – чор вакыйгасы. Беренче тапкыр бу опера җиде ел элек яңгыраган иде. Халык яратты тарихи хезмәтне. Без аны тагын да матуррак итеп дөньяга күрсәтергә тиеш, – диде ул.

Композитор Эльмир Низамовның шагыйрь Ренат Харис либреттосына язылган, режиссер Георгий Ковтун сәхнәләштергән опера Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан яндырылган уникe кыз турындагы риваятькә нигезләнгән. Риваятьләрдә, Кара пулат Болгар ханының хөкем итү урыны булган, диелә. Янгыннан соң ул «Кара пулат» дип йөртелә башлый.

Операны тере декорацияләр белән Кара пулат фонында күрсәттеләр. Гадирәк итеп әйткәндә, тарихи бина янында сәхнә корып, аны «Г» хәрефе рәвешендә ясап, яктылык эффекты булсын өчен, бинага ут төшергәннәр иде. Ачык һавадагы мәдәни чараның режиссеры – Илгиз Зәйниев.

– Безнең бердәмлек, команда белән уртак эшебез проектны тормышка ашырырга мөмкинлек бирде. Операны ачык һава өчен яраклаштыру – кызыклы тәҗрибә. Легенда тормышка ашты. Тарихи урында татар халкының бөек әсәрен күрсәтү – бик зур эш, тарихка кереп кала торган вакыйга, – дип сөйләде ул журналистларга.

Сәхнәдәге вакыйгалар Аксак Тимер Болгарга яу белән килгән чорны сурәтли. Монда традицион әкиятләргә хас ак һәм кара көчләр көрәше бара. Ак көчләрнең җиңүе белән тәмамланасы финал трагедия төсмерен алды. Ил язмышы өчен көрәшкән Турыбатыр үз үлеме белән трагик герой дәрәҗәсенә күтәрелсә, кызлар үлеме тугрылык символына әйләнде. Геройлар котылгысыз һәлакәткә дучар булсалар да, опера рухи җиңүне раслый. Кеше исеменең, кылган гамәлләренең мәңгелек икәнлеген искәртә:

«Ташлар яна, корыч яна,
суларны ялкын ялмый…
Дөнья яна, гомер яна –
кеше исеме янмый!»

Ильяс Камал җитәкчелегендәге Тинчурин театры оркестры башкаруындагы тере музыка операга драматик төсмер өстәде. Киемнәр, декорацияләр дә үзеңне чын-чынлап Болгар ханлыгы чорына эләккән кебек хис иттерде.

Операның яңа куелышында «Кара пулат»та җиде ел элек катнашкан артистларны да, яшь талантларны да күреп булды. Төп рольләрне Илүсә Хуҗина, Илгиз Мөхетдинов, Денис Ханбаба һәм Артур Исламов башкарды.

Нәргизә ролен башкаручы Илүсә Хуҗина, әсәрнең яңадан сәхнәгә кайтуы татар опера сәнгатен үстерүгә өлеш кертәчәк, дип саный.

– Тарихи җирдә беренче тапкыр татар операсын куябыз. Дулкынландыргыч, әлбәттә. Мондый вакыйга көн саен булып тормый. Команда бик зур эш башкарды. Безнең төп символ – Кара пулат. Ул безгә көч, энергия бирә, – ди ул.

Турыбатыр ролен башкаручы Илгиз Мөхетдинов әйтүенчә, спектакльнең төп яңалыгы – Кара пулатның үзе янында булуы.

– XII–XIV гасырлардан калган биналарыбыз исән чакта без аларга яңа сулыш өрергә тиеш. Бүген без бу таш пулат янында басып торуыбыз белән бик горур. Ачык һавада шундый зур проект куя алуыбыз – Татарстанның мәдәни тормышында зур вакыйга, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

# «РЕСПУБЛИКА»ГА КҮЧЕНДЕК

## КАЗАН МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ НИНДИ ЯҢАЛЫКЛАРЫ БЕЛӘН СӨЕНДЕРӘЧӘК?

**Яңа исемнәр, премьералар, милли кино индустриясенең җитешле һәм җитешсез яклары турында фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу. 7–11 сентябрьдә Татарстан башкаласында XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестивале узачак. Конкурс һәм конкурстан тыш программада барлыгы 100ләп фильм күрсәтергә ниятлиләр. Быелгы фестивальнең үзенчәлекләре турында матбугат очрашуында сөйләделәр.**

XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленә 44 илдән барлыгы 625 гариза килгән. Бу хакта Татарстан Мәдәният министрлыгының халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы Виктория Даутова хәбәр итте.

– Быел фестиваль кысасындагы фильмнар «Республика» сәүдә үзәгендә урнашкан «Синема 5» кинотеатрында күрсәтeләчәк. Тантаналы чаралар исә Казан Ратушасы һәм «Пирамида»да узачак. Шулай ук кайбер чаралар Милли китапханә, Заманча сәнгать галереясы, Милли музей, «Әкият» балалар үзәге, Казан мәдәният институтында да булыр дип көтелә, – дип сөйләде ул.

Фестивальнең сайлап алу комиссиясе рәисе Нина Кочеляева сүзләренә караганда, әлеге чарада дөньякүләм премьераларның катнашуы – фестивальнең мөһим һәм зур казанышы.

– Алай гына да түгел, быел фестивальдә Татарстанның Вьетнам һәм Казахстан белән берлектә төшерелгән фильмнары да катнаша. Бу исә Татарстан кинематографиясенең үсеше турында сөйли. Гомумән, төбәкләрдәге киноның милли продукциягә әйләнүе, аның үсеше – мөселман киносы фестиваленең соңгы еллардагы төп тенденциясе. Бу юнәлештә Татарстан бик яхшы үрнәк күрсәтә, – диде ул.

Фестивальнең башкарма директоры Миләүшә Айтуганова исә аның максатларына тукталды.

**Казан халыкара мөселман киносы фестивале – фактларда**

- ✓Әлеге чара 2005 елдан бирле уздырыла.
- ✓Фестивальнең девизы – «Мәдәниятләр диалогы аша – мәдәни диалогка».
- ✓Фестиваль программасына, авторларның нинди дин вәкилләре булуына карамастан, игелек, тынычлык һәм гаделлеккә өнди торган иң яхшы фильмнары сайлап алына.

– Әлеге фестиваль Россия өчен ислам дөньясына ишекләр ача. Ә безгә халыкара аренага чыгарга ярдәм итә. Башка илләрдәге, төбәкләрдәге кино индустриясенең хәле белән танышып, без үзебезнең үсешнең кайсы баскычында булуыбызны тәгаенли алабыз, – диде ул.

### Кем бәяли?

Быел да фестивальдә тәкъдим ителәчәк фильмнарны төрле илләрдән танылган кино тәнкыйтьчеләре, режиссерлар бәяләячәк. Алар – Хәмид Бенамра (Алжир, Франция), Анара Кашаганова (Казахстан), Әмир Салмин Әл Мурри (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), Нәркис Абьяр (Иран), Хаобам Пабан Кумар (Һиндстан), Ихсан Кабил (Төркия), Илһам Шаһин (Мисыр), Валерий Фомин (Россия), шулай ук Россия Ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин. Жюри комиссиясе рәисе – Россиянең халык артисты Владимир Хотиненко.

### Үзенчәлекләр

Халыкара мөселман киносы фестивален оештыручылар быел да шактый кызыклы программа әзерләгән. Билгеле, фестиваль кысасында конкурста катнашучы һәм конкурстан тыш күрсәтeләчәк барлык фильмнарны да тамаша кылып булачак. Керү бушлай. Моннан тыш, халыкара кинопитчинг (билгеле бер кинопроектны финансларга әзер инвесторлар табу максатыннан аны тәкъдим итү), кино мәктәпләре форумы, эшлекле мәйданчык та планлаштырылган.

– Фестивальнең тагын бер юнәлеше ул – музыка. Быел Татарстанның Милли китапханәсендә Россиянең халык артисты Ренат Ибраһимовны искә алачакбыз. Ул бит – җырчы гына түгел, актер да. Шуңа да фестиваль кысасында Ренат Ибраһимов катнашкан «Перерождение» һәм «Итальянский контракт» фильмнары күрсәтeләчәк. Шулай ук музыкаль программа да булачак. Моннан тыш, фестиваль кысасында Россиядәге джаз сәнгатенең 100 еллыгына багышланган чара уздырырга ниятлибез. Анысы Милли музейның ишегалдында булачак, – дип сөйләде Миләүшә Айтуганова.

Фестивальгә чакырылган кунаклар арасында танылган төрек актеры Нуман Чакыр, Россиянең кино һәм театр артистлары Олеся Судзиловская, Наталья Варлей, Тимур Гарәфетдинов, Иван Колесников, алып баручы Валдис Пельш (ул шулай ук Татарстан турындагы документаль фильмын да тәкъдим итәчәк), Россиянең халык артисты Александр Панкратов-Черный һәм башкалар бар.

kazan-mfmk.com

**XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленә Татарстаннан тәкъдим ителәчәк фильмнар**

Татарстан режиссерлары 40лап кинокартина тәкъдим иткән, 14 фильм программага кертелгән. Халыкара конкурста «Тарлан» (реж. – Юлия Захарова), «Галиябану» (реж. – Рифат Миндубаев), «Габдрахман» (реж. – Марсель Мәхмүтов), «Сосновый ключ» (реж. – Булат Минкин) фильмнары, ә милли конкурста «Без – 41 нче ел балалары» (реж. – Әмир Галиәскәров), «Республика 99» (реж. – Адель Таккезе, Юлия Захарова, Софья Силкина), «Параллели» (реж. – Сергей Батаев), «Посланник» (реж. – Зөфәр Хәйруллин), «Одна в горах» (реж. – Азат Дәүләтшин), «Настала ночь» (реж. – Әмир Сальянов), «Дядя Миша» (реж. – Ахмаджон Оев), «Татарский край. Троицк» (реж. – Александр Далматов), «Коридор воспоминаний» (реж. – Чыонга Тхе Тхиен), «Таш» (реж. – Елизавета Елисеева) кинокартиналары катнашачак.

### Борчыган мәсьәлә

Матбугат очрашуында Татарстан кинематографиясенең төп проблемаларына да тукталдылар. Алар турында Миләүшә Айтуганова сөйләде.

– Кино белгечләре әзерләү өлкәсендә проблемалар барлыгын аңлыйбыз. Быел без кино өлкәсендәге урта звено, ягъни куючы рәссам, гример, костюмнар буенча рәссам кебек белгечләрнең бөтенләй диярлек булмавын күрдек. Әлеге проблема бездә генә түгел. Якутия, Башкортстан, Алтайдагы коллегалар да зарлана. Гомумән, әлеге проблема Россия күләмендә бар, чөнки бу белгечләрне бездә бөтенләй әзерләмиләр, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА


**Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6688 данә**
**Гомуми тираж – 15838 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 318

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+